| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>СРЕДНЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Урта Тигәнәле ав.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 62 **20.08.2024**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 20.11.2018 ел, №88 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» (22.03.2019 ел, №104; 18.11.2019 № 117; 13.08.2020 № 133 тәге үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 20.11.2018 ел, №88 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»(22.03.2019 ел, №104, 18.11.2019 № 117; 13.08.2020 № 133 тәге үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2%:

гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле һәм сәүдә үзәкләренең (комплексларның) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацы нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарның.»

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "СРЕДНЕТИГАНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ